| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2023 п.г.т.Алексеевское № 90

**18.12.2012 ел №997 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматны мәгълүмат кулланучыга аның соравы буенча бирү тәртибе турында» Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына нигезләнеп

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 18 декабрендәге 997 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматны мәгълүмат кулланучыга аның соравы буенча бирү тәртибе» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-2.11 пунктның 8 абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 2.15 пункты белән тулыландырырга:

«2.15. Җирле үзидарә органнарының һәм аның карамагындагы оешмаларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, ведомство буйсынуындагы оешмаларның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы** **М.Р. Гайсин**